Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Советы КАРАРЫ

2019 нчы елның 25 нче октябре 268№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2017 нче елның 27 нче гыйнварындагы 80 номерлы “Торак пунктлар чикләрендә шәхси торак төзелеше, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнарга милеккә һәм арендага бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында”гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлки муниципаль районы территориясендә җирдән рациональ файдалануны оештыру максатларында, 2001 нче елның 25 нче октябрендәге 136 – ФЗ№ Россия Федерациясе Җир кодексы, 2014 нче елның 23 нче июнендәге 171-ФЗ№ “Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль закон, 2001 нче елның 25 нче октябрендәге 137 – ФЗ№ “Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” Федераль закон, 2002 нче елның 24 нче июлендәге 101 – ФЗ№ "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында" Федераль закон, 2015 нче елның 26 нчы декабрендәге108-ТРЗ№ “Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында" Татарстан Республикасы законы, 2015 нче елның 26 нчы декабрендәге109-ТРЗ№ “Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы законы, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 нче елның 12 нче гыйнварындагы 1 номерлы "Сатулар үткәрмичә генә җир кишәрлеге алуга гариза бирүченең хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында" боерыгы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2017 нче елның 27 нче гыйнварындагы 80 номерлы “Торак пунктлар чикләрендә шәхси торак төзелеше, яшелчәчелек алып бару өчен гражданнарга милеккә һәм арендага бирелә торган җир кишәрлекләренең чик күләмнәрен билгеләү турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны агросәнәгать комплексы, җирдән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы Никошин А.Ф.